**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БОРДЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«25 » август 2016 ел № 32

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 8 декабрендәге 150 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2013-2020 елларда юл хәрәкәте иминлеген арттыру» федераль максатчан программасы концепциясен раслау турында» 2012 елның 27 октябрендәге 1995-р номерлы күрсәтмәсен тормышка ашыру максатында

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең 2015 елның 8 декабрендәге 150 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Борды авыл җирлегендә 2015 - 2017 елларга юл хәрәкәте иминлеге» программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортының «Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлеген яңа редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Гомуми финанслау 1041,6 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>- район һәм авыл җирлеге бюджеты хисабына - 1041,6 мең сум |

1.1. Программанң 3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

3. Программаны финанслау.

Программаны финанслауның гомуми күләме 1041,6 мең сум тәшкил итә. Муниципаль бюджетлардан финансларны бүлү – авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе, район Башкарма комитеты җитәкчесе.

Әлеге финанслау күләмнәре тиешле финанс елына бюджетларны

формалаштырганда төгәлләштерелергә тиеш.

1.2. Бурды авыл җирлеге буенча 2015-2017 елларга юл хәрәкәте иминлеген арттыру программасын яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.Н. Әбделманова